ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 185-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Р.У. Әхмәтов, В.В. Вавилов, О.М. Воронова, А.И. Зыятдинов, А.Н. Надыршина, А.С. Созинов тарафыннан кертелгән «Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 185-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе
вазыйфаларын башкаручы М.Г. Әхмәтов

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2026 елның 22 июле
№ 688-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Р.У.Әхмәтов, В.В. Вавилов,
О.М. Воронова, А.И. Зыятдинов,
А.Н. Надыршина, А.С. Созинов
тарафыннан кертелә

**«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» 2006 елның 20 июнендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 6 (I өлеш); 2012, № 3, № 7 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 2 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш); 2025, № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

«$1^1$. Әлеге статьяның 1 өлешендәге уналтынчы абзацында күрсәтелгән вәкаләт Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

2) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән вәкаләтләр, әлеге статьяның 1 өлешендәге уналтынчы абзацында күрсәтелгән вәкаләттән тыш, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты яисә ул вәкаләт биргән Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы (органнары) тарафыннан гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2026 елның 1 сентябреннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты «Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» 2006 елның 20 июнендәге 42-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын «Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатларында эшләнде.

Әлеге Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү тәкъдим ителә, алар нигезендә Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә медицина таныклавын үткәрергә вәкаләтле медицина оешмалары исемлеген билгеләү вәкаләте гамәлгә ашырылачак.

Бер үк вакытта әлеге вәкаләт Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан мөстәкыйль башкарыла дигән нигезләмәне төшереп калдыру тәкъдим ителә.

Законның үз көченә керү датасын 2026 елның 1 сентябре дип билгеләргә тәкъдим ителә.

**«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары исемлеге**

«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарының үз көчләрен югалтуын тануны, аларны туктатып торуны, үзгәртүне яисә яңаларын кабул итүне таләп итмәячәк.

«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү «Россия Федерациясенә килгән чит ил гражданнарына һәм гражданлыгы булмаган затларга вакытлыча яшәүгә рөхсәт яисә яшәүгә рөхсәт яисә эшләүгә рөхсәт алу йә Татарстан Республикасында патент алу (аны яңадан рәсмиләштерү) өчен медицина тыныклавын үткәрүне, шул исәптән «бер тәрәзә» принцибы буенча да, оештыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 13 июнендәге 469 номерлы карарына үзгәрешләр кертүне, шулай ук Татарстан Республикасы Рәисе актын кабул итүне таләп итәчәк.

**«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында»**
**Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында»**
**Татарстан Республикасы законы проектын**
**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Халыкның санитария-эпидемиология иминлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итмәячәк.